ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 33 2018 елның 29 гыйнвары

# Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган торак урынын үзгәртеп коруга һәм (яисә) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган торак урынын үзгәртеп коруга һәм (яисә) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган кушымтада бирелгән үзгәрешләрне раслarга (6 нчы кушымта).
2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемдә калдырам.

А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елны 29 гыйнварындагы
33 номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган торак урынын үзгәртеп коруга һәм (яисә) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр

1.1. Административ регламентның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урынын үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү (килештермәү) турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»;

1.2. 1.1. пунктта «торак урынын үзгәртеп коруга һәм (яисә) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча» сүзләрен «торак урынын үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү (килештермәү) турында карар кабул итү буенча» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 1.3. пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүне башкаручы - Башкарма комитетның структур бүлекчәсе (алга таба - структур бүлекчә).

Документлар «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» ДБУның Түбән Кама филиалында (алга таба - КФҮ) кабул ителә һәм бирелә;

1.4. 1.3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.1. Башкарма комитетның урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Түбән Кама ш., Төзүчеләр пр., 12 йорт.

Структур бүлекчәнең урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Түбән Кама ш., Актүбә ур., 21 йорт.

Эш графигы:

дүшәмбе - пәнҗешәмбе: 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Тәнәфес вакыты: 12.00 дән 13.00 гә кадәр.

Белешмә өчен телефон 43-10-65.

Керү шәхесне раслаучы документлар белән.

КФҮнең урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Түбән Кама ш., Мәктәп бульвары ур., 2а йорт, 27 нче тәрәзә.

Эш графигы:

дүшәмбе, чәршәмбе, шимбә, якшәмбе: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

сишәмбе-пәнҗешәмбе: 10.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр;

җомга: 7.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр.

Белешмәләр өчне телефон: 42-45-49.

Керү ирекле.»;

1.5. 1.3.3 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитетның структур бүлекчәсе биналарында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган муниципаль хезмәт турында мәгълүматны үз эченә ала;»;

1.6. 1.3.3 пунктының 5 пунктындагы 1 абзацында «Бүлектә» сүзен «структур бүлекчәдә» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 1.3.4 пунктында «Бүлек белгече тарафыннан урнаштырыла» сүзләрен «структур бүлекчәсе белгече тарафыннан урнаштырыла» сүзләренә, «Түбән Кама шәһәренең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү департаменты» муниципаль унитар предприятиесе урыннарында» сүзләрен «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе урыннарында» сүзләренә алмаштырырга;

1.8. 1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүләр түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ЗҖ) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 29.10.2001, № 44, 4147 ст.);

2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ ШтК) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 25.12.2006, № 52 (1 өлеш), 5498 ст.);

2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба – РФ ТК) (РФ законнары җыелмасы, 03.01.2005, № 1 (1 өлеш), 14 статья);

«Россия Федерациясендә архитектура эшчәнлеге турында» 1995 елның 17 ноябрендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон белән (алга таба – 169-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 20.11.1995, № 47, 4473 ст.);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән (алга таба - 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 06.10.2003, №40, 3822 статья);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән (алга таба - 210-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст.);

Россия Федерциясе хөкүмәтенең «торак урынны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру турында гариза формасын һәм торак урынны үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү турында карар кабул итүне раслаучы документ формасын раслау хакында» 2005 елның 28 апрелендәге 266 номерлы карары (алга таба – 266 номерлы карар) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 09.05.2005, № 19, 1812 ст.);

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән (Татарстан Республикасы, № 155-156, 03.08.2004) (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР Законы);

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы (алга таба - Устав);

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – БК турында Нигезләмә).»;

1.9. 1.5 пункты түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны - документлар кабул итү һәм бирү тәрәзәсе, муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә мөрәҗәгать итүчеләргә консультация бирү;

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җибәргән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсе) кертелгән белешмәләрнең аның нигезендә кертелгән документтагы мәгълүматларга туры килмәгә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шундый башка хата).

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза (алга таба – гариза) астында муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорату аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 пункты). Гариза стандарт бланкта (1 нче кушымта) тутырыла.»;

1.10. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урынны үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү (килештермәү) турында карар кабул итү»;

1.11. «Муниципаль хезмәт күрсәтүләр стандартына таләпләр исеме» баганасының 2.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарәнең башкарма-боеру органы исеме»;

1.12. «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив акт» баганасының 2.2. пунктына «БК турында Нигезләмә» сүзләрен өстәргә;

1.13. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасындагы 2.3 пунктының икенче абзацында «һәм (яки) яңадан планлаштыру» сүзләреннән соң «(3 нче кушымта)» сүзләрен өстәргә;

1.14. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме» баганасының 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законы белән каралган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы»;

1.15. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы:

Гариза теркәлгәннән соң 45 көн. Гариза тапшыручы тарафыннан документлар күпфункцияле үзәк аша тапшырылган очракта, килештерү яки килештерүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы мондый документларны күпфункцияле үзәк тарафыннан килештерүне гамәлгә ашыручы органга тапшырганнан соң исәпләнә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.»;

1.16. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме» баганасының 2.5 пунктына «гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиеш» сүзләреннән соң «аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе» сүзләрен өстәргә;

1.17. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасын 2.5 пунктын түбәндәге эчтәлекле 9, 10 пунктлар белән тулыландырырга:

«9) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эш итсә);

10) «Ипотека (күчемсез милек залогы) турында» 1998 елның 16 июлендәге 102-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, әгәр милек закладта булган очракта, ипотека предметын барлык аерылгысыз яхшыртуга язма рәвештә банк (залог тотучы) ризалыгы.»;

1.18. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.6 пунктын түбәндәге эчтәлекнең 4 пунктчасы белән тулыландырырга:

«4) үзгәртеп корыла һәм (яисә) яңадан планлаштырыла торган торак урынның техник паспорт.»;

1.19. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган».

1.20. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.9 пунктында «Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларда хаталар яки каршылыклы мәгълүматлар ачыкланган очракта, хезмәт күрсәтүне туктатып тору башкарыла» сүзләрен «Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган» сүзләренә алмаштырырга»;

1.21. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасындагы 2.9 пунктының 5 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга: «Күрсәтелгән нигез буенча торак урынны үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерүдән баш тарту, әгәр килештерүне гамәлгә ашыручы орган мондый җавапны алганнан соң мөрәҗәгать итүчегә мондый җавап алу турында хәбәр иткән, гариза бирүчегә әлеге Кодексның 26 статьясының 2.1. өлеше нигезендә торак урынны үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны башкару өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүматны тапшырырга тәкъдим иткән, һәм гариза бирүчедән хәбәрнамә җибәрелгәннән соң унбиш эш көне эчендә андый документ һәм (яки) мәгълүмат алмаган очракта мөмкин;»;

1.22. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасындагы 2.9 пунктның 6-7 пунктчаларын төшереп калдырырга;

1.23. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасындагы 2.12 пунктының беренче, икенче абзацында «45 минут» сүзләрен «15 минут» сүзләренә алыштырырга.

1.24. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза кергән көнне»;

1.25. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме» баганасының 2.14 пунктына «, гариза бирүчеләр көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларына урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә» сүзләрен өстәргә;

1.26. «Стандарт таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмати такталар белән җиһазландырылган биналарда һәм урыннарда башкарыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (уңайлы бинага керү-чыгу һәм аларның чикләрендә хәрәкәт итү).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы булган урыннарда, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләре чикле булганнарны да исәпкә алып урнаштырыла»;

1.27. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме» баганасының 2.15 пунктына «, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның озынлыгы, муниципаль хезмәт күрсәтүне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыннарында алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып» сүзләрен өстәргә;

1.28. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге күрсәткечләре булып тора:

җәмәгать транспортының һәркем керә алырлык зонасында документлар кабул итү урынының урнашуы;

кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннар булу;

«Интернет» челтәрендәге мәгълүмати ресурсларда, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында, мәгълүмат стендларына муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башка затлар белән бертигез хезмәт күрсәтү алуга комачаулаучы киртәләрне җиңәргә ярдәм итү.

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:

гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү һәм бирү чиратлары;

муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;

муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр;

муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорату тапшырганда һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәләрен алганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр хезмәттәшлеге күздә тотыла. Аралашу озынлыгы регламент белән билгеләнә.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыннарында (алга таба – КФҮ) муниципаль хезмәт күрсәткәндә, консультация бирүне, документларны кабул итүне һәм бирүне КФҮ белгече башкара.

1.29. «Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре» 3 бүлек атамасын «, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эш урыннарында административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре» сүзләре белән тулыландырырга;

1.30. 3.1 пунктының 3.1.1 пунктчасында «Түбән Кама шәһәренең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү департаменты» (алга таба – Департамент) муниципаль унитар предприятиесе белгеченә мөрәҗәгать итәргә» сүзләрен «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе белгеченә мурәҗәгать итәргә» (алга таба – структур бүлекчәсе) сүзләренә алмаштырырга;

1.31. 3.1 пунктының 3.1.2 пунктчасында «Департамент белгеченә» сүзләрен «структур бүлекчә белгеченә» сүзләренә алмаштырырга;

1.32. 3.1 пунктының 3.1.3.-3.1.5. пунктчалары үз көчен югалткан дип танырга;

1.33. 3.1.6.-3.1.8. пунктчаларны 3.1.3-3.1.5. пунктчалар дип санарга.;

1.34. 3.1 пунктны түбәндәге эчтәлекле 3.1.6. пунктчасы белән тулыландырырга :

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге Блок-схемасы 4 нче кушымтада тәкъдим ителгән.»

1.35. 3.2 пунктының 3.2.4 пунктчасында «Департаментка тапшыра» сүзләрен «структур бүлекчәгә тапшыра» сүзләренә алмаштырырга;

1.36. 3.2 пунктының 3.2.5 пунктчасында «Департаментка тапшыра» сүзләрен «структур бүлекчәгә тапшыра» сүзләренә алмаштырырга;

1.37. 3.3 пунктының 3.3.1 пунктчасында «Бүлек белгече» сүзләрен «Структур бүлекчә белгече» сүзләренә алмаштырырга;

1.38. 3.3 пунктының 3.3.1 пунктчасында 3 нче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«үзгәртеп корыла һәм (яисә) яңадан планлаштырыла торган торак урынның техник паспорты;»;

1.39. 3.3. пунктындагы 3.3.2. пунктының өченче абзацында «Бүлеккә юнәлтелгән» сүзләрен «структур бүлекчәгә юнәлтелгән» сүзләренә алмаштырырга;

1.40. 3.4 пунктындагы 3.4.3 пунктчасының дүртенче абзацында түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«документлар пакетын структур бүлекчәгә җибәрү.»;

1.41. 3.4 пунктындагы 3.4.3 пунктының алтынчы абзацында «Бүлеккә юнәлтелгән» сүзләрен «структур бүлеккә юнәлтелгән» сүзләренә алмаштырырга;

1.42. 3.4 пунктының 3.4.4 пунктчасында «Бүлек белгече» сүзләрен «Структур бүлекчә белгече» сүзләренә алмаштырырга;

1.43. 4 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 4.5 пункты белән тулыландырырга:

«4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлеге ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу аша башкарыла.»;

1.44. 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.9 пункт өстәргә:

«5.9. Шикаятьне карау барышында яисә аны карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, тоткарланмыйча, булган материалларны прокуратура органнарына җибәрә.»

1.45. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасын яңа к4шымта итеп бирелә торган редакциядә бәян итәргә.

4 нче кушымта

# Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы

